| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2025 г. Казань № 519-28/тко-2025

2026 елга Алабуга муниципаль районы «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция һәм җитештерү программаларын эшләү, раслау һәм төгәлләштерү тәртибен, шул исәптән эшкәртү, йогышсызландыру, күмү объектларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлы һәм фактагы күрсәткечләрен билгеләү, шулай ук инвестиция һәм җитештерү программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 424 номерлы, «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карарлары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.12.2025 ел, №32-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә Алабуга муниципаль районы «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү программасын расларга.

4. Алабуга муниципаль районының «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2025 № 519-28/тко-2025
карарына 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2026 елга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/тонна | |
|---|---|---|---|
| | | 2026 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 октябрьдән |
| | Алабуга муниципаль районы | | |
| 1 | «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 955,38 | 12 040,38 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2025 № 519-28/тко-2025
карарына 2 нче кушымта

<table>
<tr><th colspan="6">Оешманың җитештерү программасы</th></tr>
<tr><th colspan="6">1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты</th></tr>
<tr><td colspan="2">Җайга салынулы оешма</td><td colspan="4">Алабуга муниципаль районы «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урнашу урыны</td><td colspan="4">423605, Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Беренче Май ур., 50 й.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җайга салучы вәкаләтле орган</td><td colspan="4">Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урнашу урыны</td><td colspan="4">420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Карл Маркс урамы, 66;</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры</td><td>башлана</td><td>01.01.2026</td><td>тәмамлана</td><td>31.12.2026</td></tr>
<tr><th colspan="6">2 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру исемлеге</th></tr>
<tr><th rowspan="2">№</th><th rowspan="2" colspan="2">Атамасы</th><th rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</th><th colspan="2">Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары</th></tr>
<tr><th colspan="2">2026 ел</th></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Объектларны агымдагы эксплуатацияләү</td><td>мең сум</td><td colspan="2">21 885,08</td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="2">Агымдагы ремонт</td><td>мең сум</td><td colspan="2">307,59</td></tr>
<tr><td>3</td><td colspan="2">Капиталь ремонт</td><td>мең сум</td><td colspan="2">0,00</td></tr>
<tr><th colspan="6">3 нче бүлек. Күмелә торган каты коммуналь калдыкларның планлаштырыла торган массасы</th></tr>
<tr><th rowspan="2">№</th><th rowspan="2" colspan="2">Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре</th><th rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</th><th colspan="2">Күрсәткеч зурлыгы</th></tr>
<tr><th colspan="2">2026 ел</th></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Каты коммуналь калдыклар массасы</td><td>мең тонна</td><td colspan="2">5,96</td></tr>
<tr><th colspan="6">4 нче бүлек. Финанс ихтыяҗлары күләме</th></tr>
<tr><th rowspan="2">№</th><th rowspan="2" colspan="2">Күрсәткечнең атамасы</th><th rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</th><th colspan="2">Күрсәткеч зурлыгы</th></tr>
<tr><th colspan="2">2026 ел</th></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Җитештерү чыгымнары</td><td>мең сум</td><td colspan="2">10 352,98</td></tr>
<tr><td>1.1</td><td colspan="2">Чимал һәм материаллар сатып алу һәм аларны саклау чыгымнары</td><td>мең сум</td><td colspan="2">1 766,24</td></tr>
<tr><td>1.2</td><td colspan="2">Электр энергиясен сатып алу чыгымнары</td><td>мең сум</td><td colspan="2">158,44</td></tr>
<tr><td>1.3</td><td colspan="2">Каты коммуналь калдыкларны күмү өчен файдаланыла торган объектлардан эксплуатацияләүгә бәйле чит оешмалар яисә шәхси эшкуарлар тарафыннан башкарыла торган эшләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнары</td><td>мең сум</td><td colspan="2">830,40</td></tr>
<tr><td>1.4</td><td colspan="2">Төп җитештерү персоналының хезмәт өчен түләү фондыннан түләнә торган хезмәт</td><td>мең сум</td><td colspan="2">5 125,31</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | өчен түләү чыгымнары һәм мәҗбүри социаль иминиятләштерүгә иминият кертемнәре | | |
| 1.5 | Займнар һәм кредитлар буенча процентлар түләүгә керемгә салым буенча салым базасын билгеләгәндә исәпкә алынмый торган чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 1.6 | Гомуми хуҗалык чыгымнары | мең сум | 2 316,39 |
| 1.7 | Башка җитештерү чыгымнары | мең сум | 156,19 |
| 2 | Ремонт чыгымнары | мең сум | 307,59 |
| 3 | Административ чыгымнар | мең сум | 3 638,52 |
| 4 | Сату чыгымнары | мең сум | 0,00 |
| 5 | Төп җитештерү билгеләнешендәге төп чараларны амортизацияләү чыгымнары | мең сум | 158,90 |
| 6 | Аренда түләвенә, лизинг түләүләренә, концессия түләвенә чыгымнар | мең сум | 2 349,11 |
| 7 | Салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 453,02 |
| 8 | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча башка операторларның товарлары, эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләү чыгымнары | мең сум | 0,00 |
| 9 | Норматив табыш | мең сум | 0,00 |
| 10 | Эшкуарларның исәпләмә табышы | мең сум | 863,01 |
| 11 | Каты коммуналь калдыкларны урнаштырганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү чыгымнары | мең сум | 591,35 |
| 12 | Алынмаган керемнәр | мең сум | 0,00 |
| 13 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | мең сум | 3 502,89 |
| 14 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый нигезләнмәгән керемнәре | мең сум | 24,68 |
| 15 | Кирәкле тулай керем | мең сум | 22 192,67 |

**5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы**

| **№** | **Чараның атамасы** | **План чоры** |
|---|---|---|
| 1 | Агымдагы ремонт | 2026 ел |

**6 нчы бүлек. Объектларның нәтиҗәлелек күрсәткечләренең план һәм факт күрсәткечләре**

| **№** | **Күрсәткечнең атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **Хакыйкый** | **План** |
| | | | **2024 ел** | **2026 ел** |
| | **Каты коммуналь калдыкларны күмү объектларының нәтиҗәлелек күрсәткечләре** | | | |
| 1 | Каты коммуналь калдыкларны кабул итүнең өзлексезлек күрсәткече | % | 100,00 | 100,00 |
| 2 | Каты коммуналь калдыкларны исәпкә алуның нәтиҗәлелеге күрсәткече | % | 50,00 | 100,0 |
| 3 | Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны минимальләштерү күрсәткече | % | х | х |

**7 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап**

Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2024 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында

| |
|---|
| берелгән. |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге